**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «30» апреленнән № 217

Торак урыны мәйданының исәп нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына торак урыны мәйданының 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә булган исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын бер гражданга торак урыны мәйданының 18 кв.метр күләмендә билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак урыннары биргәндә һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» 2006 елның 20 июнендәге 101 номерлы карарын (16.12.2011 ел, № 509 үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов